# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Дәүләткә карамаган пенсия фондлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

**1 статья.** «Дәүләткә карамаган пенсия фондлары турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 2 статьяда «активларны барлыкка китерүне, аларны инвестицияләүне» сүзләрен «пенсия резервларын формалаштыруны һәм аларны урнаштыруны» сүзләренә алмаштырырга.

2. 3 статьяда:
беренче өлештә:
«әлеге Законда» сүзләрен төшереп калдырырга;
«төп» сүзен «махсус» сүзенә алмаштырырга;

алтынчы өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Пенсия счеты - аналитик исәпләү рәвеше, ул кертемчеләрнең пенсия взнослары һәм катнашучыларга (катнашучыга) пенсия түләүләре суммаларының хәрәкәтен чагылдыра.»;

уникенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Фондның пенсия кагыйдәләре (алга таба фонд кагыйдәләре) - фонд тарафыннан дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү буенча йөкләмәләрне үтәү тәртибен һәм шартларын билгеләүче закон таләпләрен исәпкә алып, фонд тарафыннан раслана һәм теркәлә торган документ.»;

унөченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Идарә итүче компания (алга таба - идарәче) - билгеләнгән тәртиптә тиешле рөхсәтләр (лицензияләр) алган һәм фонд (фондлар) белән шартнамә төзү нигезендә фондның (фондларның) пенсия резервлары белән идарә итүне гамәлгә ашыручы хуҗалык җәмгыяте рәвешендәге коммерциячел оешма.»;

136

Түбәндәге эчтәлектә ундүртенче һәм унбишенче яңа өлешләр өстәргә:

«Депозитарий - депозитарий эшчәнлеген гамәлгә ашырып, кыйммәтле кәгазьләр базарында профессиональ катнашучы, ул эшчәнлек кыйммәтле кәгазьләрнең сертификатларын саклау һәм (яисә) исәпкә алу һәм кыйммәтле кәгазьләргә хокуклар күчү буенча хезмәтләр күрсәтүдән гыйбарәт. Юридик зат кына депозитарий була ала.

Бәйсез актуарий (алга таба - актуарий) - законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, тиешле рөхсәтләре (лицензияләре) булган һәм фондлар тарафыннан кертемчеләр һәм катнашучылар алдында кабул ителгән йөкләмәләрне, пенсия резервларын формалаштыру тәртибен, пенсия взносларын берләштерүне һәм дәүләткә карамаган пенсияләрне, сатып алу суммаларын түләүләрне актуар бәяләүне, шулай ук фондларның һәм идарәчеләрнең инвестиция сәясәтен актуар бәяләүне гамәлгә ашыручы юридик зат яисә индивидуаль эшкуар.»;

ундүртенче өлешне уналтынчы өлеш дип санарга һәм анда «Татарстан Республикасының,» «(алга таба – вәкаләтле дәүләт органы)» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. II бүлекнең исемендә «фондларны» сүзен «фондны» сүзенә алмаштырырга.

4. 4 статьяда:

статья исемендә һәм беренче өлештә «фондларны» сүзен «фондны» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлектә яңа икенче өлеш өстәргә:

«Гамәлгә куючыларның (гамәлгә куючының), фондка тапшырылып, фонд милкенә әверелгән мөлкәткә хокуклары булмый.»;

икенче, өченче өлешләрне өченче, дүртенче өлешләр дип санарга.

5. 6 статьяның икенче өлешендә «әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән» сүзләрен «дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү буенча» сүзләренә алмаштырырга.

6. 10 статьяда:

беренче өлештә:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- үз акчаларын, пенсия резервларын да кертеп, мөстәкыйль яисә идарәче (идарәчеләр) аша формалаштыра һәм урнаштыра;»;

җиденче абзацны төшереп калдырырга;

уникенче абзацта:

«әлеге Законга» сүзләрен «законнарга» сүзенә алмаштырырга;

икенче өлешне төшереп калдырырга.

7. 11 статьяда:

беренче өлешне төшереп калдырырга;

икенче өлешкә түбәндәге эчтәлектәге абзацларны өстәргә:

«- пенсия резервларын формалаштыру тәртибе турында нигезләмәләр;

- пенсия счетларын алып бару, кертемчеләргә һәм катнашучыларга аларның торышы турында хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмәләр;

- пенсия резервларының юнәлешләре һәм аларны урнаштыру тәртибе турында нигезләмәләр;

- сатып алу суммасын исәпләү тәртибе турында нигезләмәләр;

- кертемчеләргә һәм катнашучыларга идарәче турында һәм хезмәт күрсәтүләр буенча фонд белән шартнамәләр төзегән депозитарий турында мәгълүмат бирү хакында нигезләмәләр;

- фондның йөкләмәләрен актуар исәпләүне башкару методикасы;

- фонд, идарәче һәм депозитарий хезмәтләренә түләү күләмен билгеләү нормативлары».

8. 13 статьяда:

беренче өлештә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пенсия схемаларының төп төрләре түбәндәгеләр:»;

икенче абзацта «фондның инвестиция керемен исәпләү» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлектә яңа икенче өлеш өстәргә:

«Пенсия схемалары төрләре законнар нигезендә фонд кагыйдәләре белән билгеләнә.»;

икенче өлешне өченче олеш дип санарга.

9. 14 статьяда:

икенче өлештә «исемле» сүзен «солидар (исемле)» сүзләренә алмаштырырга;

өченче өлешне төшереп калдырырга;

дүртенче өлешне өченче өлеш дип санарга һәм «исемле» сүзен «солидар (исемле)» сүзләренә алмаштырырга.

10. 15 статьяда:

статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 статья. Фонд мөлкәте»;

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фонд мөлкәте пенсия резервларыннан һәм фондның устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәттән тора.»;

икенче өлештә:

беренче абзацта «активыннан» сүзен «резервларыннан» сүзенә алмаштырырга.

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«пенсия взносларын урнаштырудан керем;»;

өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фондның устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт түбәндәгеләр исәбеннән барлыкка килә:

- гамәлгә куючыларның (гамәлгә куючының) күмәк кертеме;
- кертемчеләрнең максатчыл взнослары, фонд кагыйдәләре нигезендә фонд чыгымнарын каплау өчен кулланылучы пенсия резервларын урнаштырудан фонд кереме өлеше;
- фондның устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәтне файдаланудан фонд кереме;
- хәйрия взнослары һәм башка законлы кертемнәр.»;

дүртенче өлешне төшереп калдырырга.

11. 16 статьяда:

статьяның исемендә «фондның пенсия активлары» сүзләрен «резервлар» сүзенә алмаштырырга;

беренче-өченче өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фондлар пенсия резервларын мөстәкыйль яисә ышанычлы идарәче шартнамәләре, йөкләмә шартнамәләре һәм башка төрле шартнамәләр буенча законнар нигезендә идарәче (идарәчеләр) аша урнаштырырга хокуклы.

Идарәченең (идарәчеләрнең) законнарда билгеләнгән таләпләр нигезендә кирәкле рөхсәтләре (лицензияләре) булырга тиеш.

Пенсия резервларын урнаштыру буенча фондларның эшчәнлеге эшкуарлык эшчәнлегенә керми. Пенсия резервларын урнаштыру тәртибе законнар нигезендә билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлектә яңа дүртенче өлеш өстәргә:

«Пенсия резервларыннан фондның, кертемчеләрнең, идарәченең (идарәчеләрнең) һәм депозитарийның бурычлары буенча түләү алынмый.»;

дүртенче өлешне бишенче өлеш дип санарга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идарәче (идарәчеләр) үзенә (үзләренә) йөкләнгән йөкләмәләр өчен законнар нигезендә фонд (фондлар) һәм анда (аларда) катнашучылар алдында җавап бирә (бирәләр). Идарәче (идарәчеләр) фондның (фондларның) йөкләмәләре буенча катнашучылар алдында җавап бирми (бирмиләр).»;

бишенче өлешне төшереп калдырырга.

12. 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 статья. Пенсия резервларын урнаштырудан керемне бүлү

Пенсия резервларын урнаштырудан алынган керем пенсия резервларын тулыландыруга һәм фонд эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны каплауга фонд кагыйдәләре нигезендә җибәрелә.

Фонд эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны каплау фондның устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәттән файдалану һәм пенсия резервларын урнаштырудан алынган керем исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Бу очракта фондның устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәтне формалаштыруга күчерелүче суммалар фонд эшчәнлегенең беренче өч елында пенсия резервларын урнаштырудан алынган керемнең 20 процентыннан һәм киләчәктә пенсия резервларын урнаштырудан алынган керемнең 15 процентыннан артмаска тиеш.».

13. 18 статьяның беренче өлешендәге икенче абзацында һәм өченче өлешендә «әлеге Закон» сүзләрен «законнар» сүзләренә алмаштырырга.

14. 19 статьяда:

икенче өлешкә түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«- фондтан пенсия шартнамәсе буенча фонд йөкләмәләрен тулы күләмдә үтәүне таләп итәргә;

- фонд алдында үз мәнфәгатьләрен һәм үзендә катнашучыларның мәнфәгатьләрен күтәрергә, фонд гамәлләренә шикаять бирергә;

- фондтан сатып алу суммаларын башка фондка күчерүне таләп итәргә»;

дүртенче өлештә:

икенче өлештә «әлеге Закон» сүзләрен «законнар» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- фондтан пенсия шартнамәсе шартлары нигезендә дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты буенча фонд йөкләмәләрен үтәүне таләп итәргә;

- фондтан фонд кагыйдәләре һәм пенсия шартнамәләре шартлары нигезендә дәүләткә карамаган пенсия тәэминаты шартларын үзгәртүне таләп итәргә;

140

- фондтан сатып алу суммаларын түләүне яисә башка фондка күчерүне таләп итәргә».

15. 21 статьяда:

түбәндәге эчтәлектә икенче һәм өченче яңа өлешләр өстәргә:

«Фонд бухгалтерлык исәбен тормышка ашырганда фондның устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәтне һәм пенсия резервларын тәшкил итүче мөлкәтне катнаштыруга юл куймаска тиеш.

Фонд һәр пенсия схемасы буенча пенсия күләмнәренең беркетелгән күләме белән пенсия җыелмаларын, булдырылган пенсия резервларын һәм түләнгән пенсияләрне исәпкә алып бара.»;

икенче өлешне дүртенче өлеш дип санарга;

түбәндәге эчтәлектә бишенче-җиденче яңа өлешләр өстәргә:

«Фонд вәкаләтле дәүләт органына актуарий уздырган актуар бәяләү нәтиҗәләре буенча елга бер тапкыр бәяләмә тапшыра. Күрсәтелгән бәяләмә фондның еллык хисабының аерылгысыз өлеше булып тора.

Идарәче пенсия резервларын тәшкил итүче мөлкәтне, үзләренең мөлкәтен, шулай ук үз идарәсендә булган башка мөлкәтне аерым-аерым, аларны катнаштыруга юл куймыйча, исәпкә алып барырга тиеш.

Фондка хезмәт күрсәтүче депозитарий пенсия резервларын тәшкил итүче, үзләренең мөлкәтен, шулай ук аның белән шартнамә төзегән башка затлар мөлкәтен аерым-аерым, аларны катнаштыруга юл куймыйча, исәпкә алып барырга тиеш»;

өченче өлешне сигезенче өлеш дип санарга.

16. VI бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VI бүлек. Фондның дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү буенча йөкләмәләрен үтәү гарантияләре».

17. 24 статьяның икенче, өченче өлешендә «активларының» сүзен «резервларының» сүзенә алмаштырырга.

18. 25 статьяда:

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү буенча кабул ителгән йөкләмәләрне үтәү өчен фонд пенсия резервлары булдыра.»;

икенче олештә «мөстәкыйль» сүзен «законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче өлештә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «законнар» сүзенә алмаштырырга.

141

19. 26 статьяда:

икенче өлештә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан» сүзләрен «законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче, дүртенче өлешләрне төшереп калдырырга.

20. 27 статьяның өченче өлешендә «активлары» сүзен «резервлары» сүзенә алмаштырырга.

21. Түбәндәге эчтәлектә $27^1$ статья өстәргә:

«$27^1$ статья. Фонд эшчәнлеген актуар бәяләү

Фондлар финанс елы нәтиҗәләре буенча ел саен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү эшчәнлеге нәтиҗәләренә һәм пенсия резервларын урнаштырудан керемнәргә актуар бәяләү уздырырга тиеш.

Актуар бәяләү актуарий тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

22. 29 статьяның беренче, өченче өлешләрендә «әлеге Закон» сүзен «законнар» сүзенә алмаштырырга.

23. Түбәндәге эчтәлектә $30^1$ статья өстәргә:

«$30^1$ статья. Фондларның һәм идарәчеләрнең монополия эшчәнлеген һәм аларның намуссыз конкуренциясен кисәтү, чикләү һәм булдырмый калу

Фондларның һәм идарәчеләрнең монополия эшчәнлеген һәм аларның намуссыз конкуренциясен кисәтү, чикләү һәм булдырмый калу башкарма хакимиятнең махсус вәкаләтле федераль органы тарафыннан тәэмин ителә.».

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 27 сентябре
№ 1078